«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
________ А.Х. Гыйльметдинов

"20" гыйнвар 2012 нче ел

# Рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен контроль бәяләү материалларының күрсәтмә варианты

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан әзерләнде

# Рус телендә гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе уздыру өчен контроль бәяләү материалларының күрсәтмә варианты

## 2012 нче елгы дәүләт (йомгаклау) аттестациясе өчен татар теленнән контроль бәяләү материалларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар

2012 нче елгы дәүләт (йомгаклау) аттестациясе өчен татар теленнән контроль бәяләү материалларының күрсәтмә варианты белән танышканда, шуны истә тотыгыз: тәкъдим ителгән биремнәр 2012 нче елда контроль бәяләү материалларының вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын чагылдырмыйлар. 2012 нче елгы дәүләт (йомгаклау) аттестациясендә тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпләрнең татар төркемнәрендәге IX сыйныф укучылары өчен дәүләт (йомгаклау) аттестациясенә ә зерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының Кодификаторында тәкъдим ителгән.

Күрсәтмә вариант дәүләт (йомгаклау) аттестациясенең теләсә кайсы катнашучысына һәм киң җәмәгатьчелеккә контроль бәяләү материалларының структурасы, биремнәр саны, аларның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу варианттагы киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрне үтәүнең бәяләү критерийлары киңәйтелгән җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

Бу мәгълүматлар чыгарылыш сыйныф укучыларында дәүләт (йомгаклау) аттестациясенә әзерлек осталыгын булдырачак.

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН
## яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясе

### Эшне башкару өчен күрсәтмә

Имтиханны тапшыруга 4 сәгать (240 минут) вакыт бирелә. Бу вакыт эчендә ук учылар 3 өлештән торган эшне башкарып чыгарга тиеш.

Беренче бүлек 11 биремне (А1–А11) үз эченә ала. Һәр биремгә китерелгән 4 вариант җавапның берсе, ягъни дөресе генә сайланып алынырга тиеш. Биремне үтәгән вакытта сайлап алынган җавапның номерын түгәрәкләп куегыз. Әгәр кирәкле номерны дөрес билгеләмәсәгез, түгәрәкләнгән номерны сызыгыз, шуннан соң дөрес җавапны түгәрәкләгез.

Икенче бүлек 12 биремнән (В1–В12) гыйбарәт. Әлеге биремнәргә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга кирәк. Бу биремнәргә җавапларны имтихан эшендәге махсус урынга сан яки сүз белән языгыз. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга кирәк.

Өченче бүлек бер биремнән (С1) гыйбарәт һәм текстка бәйле зур булмаган язма эшне (сочинение) тәшкил итә.

Имтиханда орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне үтәгәндә, караламадан файдаланырга ярый. Шуны истә тотыгыз: караламадагы язмаларыгыз эшне бәяләгәндә исәпкә алынмаячак.

Биремнәрне бирелгән тәртиптә үтәргә киңәш ителә. Аларны үтәү барышында кыенлык туса, биремне калдырып торып, алдагысына күчегез. Вакыт калган очракта, бу биремнәргә кабат әйләнеп кайту мөмкинлеге бар.

Балларны бергә кушканнан соң, гомуми балл чыгарыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

**Уңышлар телибез !**

## 1 нче бүлек

| *Текстны укыгыз һәм А1-А11; В1-В12; С1 биремнәрен үтәгез.* |
|---|

### Шомырт нигә елый?

(1) Зәй буендагы ялгыз шомырт төбенә палаткабызны корып, җәен бик күңелле ял иткән идек без. (2) Мин кармак салып утырам, улым чикерткәләр куа, зәңгәр-кызыл тубын чөеп уйный, кошлар белән нидер сөйләшә, арыгач, шомыртның күләгәсенә ятып йоклый.

(3) Шул көннәрдән бирле шомырт якын дустыбызга әйләнде, һәм без улым белән һәр яз шомыртыбызның хәлен белергә бара торган булдык. (4) Шомырт безне бик куанып каршылый, нәни яфраклы ботакларын селкетеп, безне сәламли.

(5) Аннары без шомыртыбыз янына аның шау чәчәккә төренер вакытын чамалап киләбез. (6) Бу вакытта әле чияләр, алмагачлар, миләшләр үзләренең чәчәк бөреләрен ачар-ачмас кына утыралар. (7) Бу дөньяда үзләре генә белә торган тантана көннәрен көтәләр алар.

(8) Җәй азакларына таба да без шомыртыбызга кунакка киләбез. (9) Дустыбыз безне, авызны бераз бөрештерсә дә, бик тәмле чем-кара җимешләре белән сыйлый.

(10) Быел шомыртыбызның яфрак ярган шатлыгын уртаклашырга бара алмадык. (11) Шунлыктан аның мул чәчәкле хуш исле бәйрәменә вакытында барып җитәргә ашыктык.

(12) Шатлыгын уртаклашырга дип килсәк тә, шомыртның би к моңаеп утырганын күрдек без. (13) Дустыбызның бәйрәменә соңга калдыкмы? (14) Әнә бит, инде чәчәк таҗларын коеп бетерә язган ул.

(15) Килеп җитүгә, дустыбыз каршында башларыбызны иеп, сүзсез калдык. (16) Юк, чәчәкләрен коймаган шомырт, аны талаганнар. (17) Ботагы белән сындырып алып, кул җитәрдәй бөтен чәчәкләрен урлап киткәннәр. (18) Урлар чәчәк калмагач <…> кайсыдыр тагын да өскәрәк үрмәләгән һәм шомыртның бер ботагын сындырып ук төшергән. (19) Ул каерылган ботак җиргә үк салынып төшкән, яфраклары йөзләрен җыерганнар. (20) Каерылган урындагы кызгылт-сары җәрәхәттән, дымланып, кан саркый сыман. (21) Тал-тирәк арасында ниндидер кошлар моңсу гына сайрый, бөтен Зәй буе моңсуланып калган иде. (22) Акрын гына шомыртыбыз янына атладык.

(23) – Шомырт... елый, – диде улым, агачның һәр ботагында җемелдәгән тамчыларга карап, үзенең дә күзләреннән чыккан күз яшьләрен сөрткәләп алды.

(24) Әйе, елый иде шомырт...

(Р. Төхфәтуллиннан)*

***Төхфәтуллин Рафаил** (1924-1994) – прозаик. Әсәрләрендә сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышының, кешеләрнең хезмәткә, туган җиргә мөнәсәбәтләрен чагылдырган. Язучы «Бөтнек үләне исе», «Агымсу», «Акбүз ат» һ.б. әсәрләрендә замана проблемаларын үзенчәлекле образлар аша биргән.

***Текст эчтәлегенә нигезләнеп, A1-A11 биремнәрен үтәгез. A1-A11 биремнәренә җавап 4 вариантта тәкъдим ителә, шуларның берсе генә дөрес. Дөрес җавапның номерын түгәрәккә алыгыз.***

**A1**

Кайсы җөмлә түбәндәге сорауга җавап була ала?
***Шомырт нигә елый?***

1) Ботагы белән сындырып алып, кул җитәрдәй бөтен чәчәкләрен урлап киткәннәр.
2) Бу вакытта әле чияләр, алмагачлар, миләшләр үзләренең чәчәк бөреләрен ачар-ачмас кына утыралар.
3) Тал-тирәк арасында ниндидер кошлар моңсу гына сайрый, бөтен Зәй буе моңсуланып калган иде.
4) Дустыбызның бәйрәменә соңга калдыкмы?

**A2**

**Хаталы** билгеләмәне табыгыз.

1) *Шомырт* сүзендә икенче иҗектә килгән [ы] авазы [о]лашып әйтелә.
2) *Яфрак* сүзендә авазлар һәм хәрефләр саны бертигез.
3) *Сәламли* сүзендә әйтелеш белән язылыш аерыла.
4) *Башларыбызны* сүзендә кулланылган сузыклар калынлыкта ярашалар.

**A3**

**Саңгырау** тартык авазлар гына кергән сүзне табыгыз.

1) палатка
2) кармак
3) миләш
4) чәчәк

**A4**

**Хаталы** сүзтезмәне табыгыз.

1) һәр ботак
2) шомырт төбө
3) якын дус
4) бөтен чәчәкләрен

**A5** *Дөнья* сүзендә ***ь хәрефе*** ни өчен язылган?

1) һәмзә тартыгын белдерә
2) иҗекне нечкәртә
3) тартыкны нечкәртә
4) аеру билгесе булып тора

**A6** **Кушма сүзне** билгеләгез.

1) язгы
2) ялгыз
3) алмагач
4) кызыл

**A7** ***"Әйе, елый иде шомырт"*** җөмләсенең дөрес тәрҗемәсен билгеләгез.

1) Да, черемуха плакала.
2) Да, черемуха горевала.
3) Да, черемуха плачет.
4) Да, черемухи плачут.

**A8** **Төшем килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне билгеләгез.

1) тамчыларга карау
2) чәчәкләрен урлап китү
3) дустыбызның бәйрәме
4) яфраклы ботаклар

**A9** Калын хәрефләр белән бирелгән **фигыльнең төрен** билгеләгез.
*Бу дөньяда үзләре генә* ***белә торган*** *тантана көннәрен көтәләр алар.*

1) сыйфат фигыль
2) хәл фигыль
3) исем фигыль
4) инфинитив

**A10** ***Дустыбызның бәйрәме*** сүзтезмәсенең дөрес тәрҗемәсен табыгыз.

1) праздник вашего друга
2) праздник нашего друга
3) праздник их друга
4) праздник моего друга

**A11** **Сыйфатны** табыгыз.

1) кызгылт-сары
2) каерылган
3) дымланып
4) сыман

## 2 нче бүлек

***B1–B12 биремнәрен укылган текст нигезендә башкарыгыз. Җавапларны сүз (сүзтезмә) яки саннар белән языгыз.***

**B1** 4 нче җөмләдән *шатланып, сөенеп* сүзләренә **синоним** булган берәмлекне табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B2** 12 нче җөмләдән *кайгысын, хәсрәтен* сүзләренә **антоним** булган берәмлекне табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B3** 1 нче җөмләдән **алмашлыкны** табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B4** 8 нче җөмләдән **баш кисәкләрне** табып языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B5**

5-7 нче җөмләләр арасыннан **тиңдәш кисәкләр** булган җөмләнең номерын языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B6**

10-14 нче җөмләләр арасыннан **сорау җөмләнең** номерын языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B7**

**Аерымланган хәлгә** бәйле куелган өтернең номерын языгыз.

*Шатлыгын уртаклашырга дип килсәк тә, (1) шомыртның бик моңаеп утырганын күрдек без. Дустыбызның бәйрәменә соңга калдыкмы? Әнә бит, (2) инде чәчәк таҗларын коеп бетерә язган ул.*

Җавап: ______________________________.

**B8**

**Туры сөйләмле** җөмләнең номерын языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B9**

3 нче җөмләдә ничә **гади җөмлә** бар? Җавапны сан белән языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B10**

8 нче җөмләдәге **әйтелеше язылышына** туры килмәгән сүзне языгыз.
Җавап: ______________________________.

**B11**

18 нче җөмләдә <…> тамгасы урынына кайсы **тыныш билгесе** куелырга тиеш? Җавапны сүз белән языгыз.

Җавап: ______________________________.

**B12**

Кушма җөмлә составындагы **гади җөмләләр арасына** куелган өтернең номерын языгыз.

*Ул каерылган ботак җиргә үк салынып төшкән, (1) яфраклары йөзләрен җыерганнар. Каерылган урындагы кызгылт-сары җәрәхәттән, (2) дымланып, (3) кан саркый сыман.*

Җавап: ___________________________.

***1 һәм 2 нче бүлек биремнәренә (А һәм В тибындагы) җавапларыгызны 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз.***

## 3 нче бүлек

***Укылган текстны файдаланып, С1 биремен үтәгез. Әлеге биремнең җавабын 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.***

**C1**

**“Шомырт... елый, - диде улым, агачның һәр ботагында җемелдәгән тамчыларга карап, үзенең дә күзләреннән чыккан күз яшьләрен сөрткәләп алды.**

**Әйе, елый иде шомырт...”** Текст ахырында китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезнераслый торган 2 дәлил китерегез. Мисаллар китергәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын табыгыз.

Сочинениенең күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш. Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

# Татар теленнән имтихан эшен бәяләү системасы

## 1 нче бүлек

### А1-А11 биремнәрен тикшерү

Имтихан эшенең А1-А11 биремнәрен **дөрес** үтәгән өчен, һәр биремгә 1 балл, **җавап хаталы булса** яки **бөтенләй булмаса,** 0 балл куела.

Дөрес эшләнгән 11 бирем өчен, укучыга 11 балл куела.

Ике яки аннан да күбрәк җавап (шул исәптән дөрес җавап та) билгеләнеп, хата җаваплар сызылмаган очракта җавап дөрес дип саналмый.

*1 нче таблица*

| Биремнең номеры | Дөрес җавап |
|---|---|
| А1 | 1 |
| А2 | 2 |
| А3 | 4 |
| А4 | 2 |
| А5 | 4 |
| А6 | 3 |
| А7 | 1 |
| А8 | 2 |
| А9 | 1 |
| А10 | 2 |
| А11 | 1 |

## 2 нче бүлек

### В1-В12 биремнәрен тикшерү

Имтихан эшенең В1-В12 биремнәрен **дөрес** үтәгән өчен, һәр биремгә 1 балл, **җавап хаталы булса** яки **бөтенләй булмаса,** 0 балл куела.

Дөрес эшләнгән 12 бирем өчен, укучыга 12 балл куела.

*2 нче таблица*

| | |
|---|---|
| В1 | куанып |
| В2 | шатлыгын |
| В3 | без |
| В4 | без киләбез |
| В5 | 6 |
| В6 | 13 |

| | |
|---|---|
| B7 | 1 |
| B8 | 23 |
| B9 | 2 |
| B10 | шомыртыбызга |
| B11 | өтер |
| B12 | 1 |

**3 нче бүлек**

**С1 биремен тикшерү**

С1 бирeменә җавап түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә.

*3 нче таблица*

| № | **Текст эчтәлеген анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (С1) бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| **С2К1[1]** | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлаткан. Аңлатмада хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген гомумән дөрес аңлаткан,<br>**ләкин**<br>аңлатмада 1 хатасы бар. | 1 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлатмаган,<br>**яки**<br>имтихан бирүче, тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген аңлатканда, 2 яки күбрәк хата ясаган,<br>**яки**<br>тексттан алынган кисәк эчтәлегенең аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |
| **С2К2** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Имтихан бирүче башка тексттан дәлил (-ләр)-мисаллар (-лар) китергән. | 1 |

[1] С1.2 биремен бәяләү өчен беренче критерий

| | | |
|---|---|---|
| | Имтихан бирүче тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән,<br>**яки**<br>имтихан бирүче биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән. | 0 |
| **С2К3** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| **С2К4** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтенлек һәм тәгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтенлек һәм тәгәлләнгән,<br>**ләкин**<br>текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| | **С2К1-С2К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | **9** |

Игътибар!

Әгәр сочинениедә текст күчереп кенә язылса яки анда текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча (С2К1-С2К4; ГК1-ГК4, ФК1) 0 балл белән бәяләнә.

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге** аерым бәяләнә (4 нче таблицаны кара).

*4 нче таблица*

| № | Имтихан бирүче сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| | **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә (ГК1–ГК4), **сочинениенең күләмен** истә тотарга кирәк.

4 нче таблицада бирелгән нормативлар сочинениедә 100 һәм күбрәк сүз булган очракта тәкъдим ителә.

Әгәр сочинениедә 50-99 сүз булса, ГК1–ГК4 критерийлары буенча 1 дән артык балл куелмый.

Әгәр сочинениедә 50 дән кимрәк сүз булса, ГК1–ГК4 критерийлары буенча мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Барлык эш өчен, имтихан бирүче ала алган **иң югары балл – 42.**